| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

03.11.2022 № 712-р

«Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гаиләләргә ярдәм күрсәтү турында» Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 10.10.2022 № 656-р күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Кечләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 20.10.2022 № 1122 карары нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

БОЕРЫК БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1нче пунктындагы 1.2 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мәгариф оешмаларында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә елешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләсенә иждивениедә булган балаларны карау һәм тәрбияләгән ечен алына торган түләүдән ата-аналарны (законлы вәкилләрдән) азат итәргә.» үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1 пунктындагы 1.3 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә: «Нурлат муниципаль районы башкарма хакимияте органнары карамагындагы муниципаль белем бирү оешмаларында елешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның 1 - 11 сыйныфта белем алучы балаларына ике тапкыр кайнар ризык (иртәнге аш, тешке аш) белән түләүсез туклануны тәэмин итәргә».

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1 пунктындагы 1.5 пунктчасына үзгәрешләр кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль, дәүләт мәдәният һәм ял итү учреждениеләрендә музейларга, театрларга, концертларга гаилә әгъзаларына (хатыны, балалары, ата-анасы, әбисе һәм бабасы) бушлай бару».

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1

пунктындагы 1.7 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә: «Гаилә әгъзаларына (хатыны, балалары, ата-аналары, әбисе һәм бабасы) эш эзләүдә ярдәм итү.».

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1 пунктындагы 1.9 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Өлкән яшьтәге туганнарына, инвалидлар һәм инвалид балалар өчен:

- Нурлат муниципаль районында «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге тарафыннан мобилизацияләнгән гражданның якын туганнарына (әни, әти, әби, бабай һәм инвалид бала) өйгә барып бушлай хезмәт күрсәтү.».

6. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1 пунктындагы 1.10 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә: «Гаиләнең барлык әгъзалары (хатыны, балалары, ата-аналары, әбиләре һәм бабалары) өчен «Ышаныч» үзәге тарафыннан «Кайнар линия» номеры буенча психологик ярдәм күрсәтелү: 8(84345) 2-60-61.».

7. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 10 октябрендәге 656-р номерлы боерыгының 1 пунктындагы 1.11 пунктчасына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә: «Гаиләсенә (хатыны, балалары, ата-аналары, әбиләре һәм бабалары) социаль һәм башка түләүләрне, социаль ярдәм чараларын рәсмиләштерүдә булышлык күрсәтү.».

8. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы З.Р. Сәйфетдинова